«АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»
№02 (412) | **21–27 гыйнвар** 2022 ел

Республика яңалыклары –
**www.tatar-inform.tatar** сайтында

Кулланучы хәбәрләре

# Туй күлмәге пычранса...

**«Туй күлмәгемне химик юл белән чистартуга биргән идем. Аны алырга килгәч, күлмәктә караңгы төстәге таплар барлыкка килгәнен күрдем. Бу кимчелекне бетерүне сорагач, хезмәткәрләр баш тартты. Химчистка җитәкчелегенә шикаять яздым, әмма әлеге оешма администрациясе тарафыннан бернинди дә җавап булмады. Бу очракта оешма хезмәткәрләре җаваплымы? Алга таба нәрсә эшләргә?**

**Алена К.»**



Россия Федерациясенең «Кулланучы хокукларын яклау» турындагы законының 35 маддәсе буенча, кулланучыдан алынган материалны (әйберне) тулысынча яки өлешчә югалткан (бозган) өчен башкаручы өч көн эчендә аны шундый ук сыйфаттагы шундый ук материал (әйбер) белән алмаштырырга һәм кулланучы теләге буенча шундый ук материалдан яңаны эшләп бирергә тиеш. Ә шундый ук сыйфаттагы материал (әйбер) булмаган очракта, ул кулланучыга шушы югалтылган (бозылган) әйбернең бәясен икеләтә түләргә һәм кулланучы тарафыннан тотылган чыгымнарны капларга тиеш.

Бу очракта, химчистка җитәкчелегеннән җавап булмагач, сез судка мөрәҗәгать итә аласыз (Россия Федерациясе Граждannар Кодексының 11 маддәсе).

РФ Законының 17 маддәсенең 2 пункты нигезендә, сез теркәлү яки яшәү урыныгыз яисә җавап бирүченең урнашу урыны, йә булмаса килешү төзү яки үтәү урыны буенча судка дәгъва белдерергә хокуклы. РФ Законының 17 маддәсенең 3 пункты нигезендә, судка дәгъва белән мөрәҗәгать иткәндә, кулланучылар үз хокукларын бозуга бәйле эшләр буенча дәүләт пошлинасы түләүдән азат ителә.

**Моннан тыш, РФ Законының 15 маддәсе нигезендә, кулланучы әхлакый зыян өчен компенсация алырга да хокуклы. Аның күләмен суд билгели һәм ул матди зыянның күләменә бәйле булмый.**